ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**Татарстан Республикасы Экология кодексының 119 статьясына үзгәреш кертү турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 14 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Экология кодексының 119 статьясындагы 3 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 1; 2010, № 5 (I өлеш); 2011, № 6 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 1; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 4; 2016, № 1 – 2, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш), № 44 (I өлеш); 2017, № 27 (I өлеш); 2018, № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“3. Урманнардан файдалануны гамәлгә ашыручы гражданнар, юридик затлар тарафыннан урман хуҗалыгы регламентын һәм урманнарны үзләштерү проектын үтәмәү урман кишәрлеген арендалау шартнамәләрен яисә урман үсентеләрен сату-алу шартнамәләрен вакытыннан алда өзү өчен, шулай ук урман кишәрлегеннән даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану яисә урман кишәрлегеннән түләүсез файдалану хокукын ирексез туктату, гавами сервитутны бетерү өчен нигез булып тора.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан, Кремль
2019 ел, 01 март
№ 5-ТРЗ